**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 30**

## I. Тестны эшләгез.

1. Текстта [ғ] авазы кергән ничә сүз бар? **(1 балл)**
а) **4**
ә) 5
б) 8

2. Йолдыз сүзенең дөрес бирелгән транскрипциясен табыгыз. **(1 балл)**
а) йолдыз – [йолдыз]
ә) йолдыз – [йолдыс]
б) **йолдыз – [йолдоз]**

3. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**
а) яфрак
ә) туган
б) **йоклый**

4. Калын һәм нечкә сузык авазларның парлары дөрес булган рәтне табыгыз. **(1 балл)**
а) [а] – [ә], [о] – [ө], [у] – [ү], [ы] – [и]
ә) **[а] – [ә], [о] – [ө], [у] – [ү], [ы] – [э]**
б) [а] – [ә], [о] – [э], [у] – [ү], [ы] – [ө]

5. Басым дөрес куелган рәтне билгеләгез. **(1 балл)**
а) **ба́рмый, нә́рсә, киттéме, ру́сча**
ә) а́шамый, нинди́, ки́ләме, татарча́
б) сөйләми́, кайсы́, барамы́, и́нлизчә

6. *Түбән* сүненең антонимын табыгыз. **(1 балл)**
а) уңда
ә) **югары**
б) янәшә

7. *Улү* сүзенең синонимын билгеләгез. **(1 балл)**
а) түзү
ә) яшәү
б) **вафат булу**

8. Составында форма ясагыч кушымча булган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**
а) милләттәш
ә) **үзәнлекләр**
б) йокла

9. Ясалма нигезле сүзне табыгыз. **(2 балл)**
а) авыл
ә) авылга
б) **авылдаш**

**II. Теоретик бирем. (4 балл)**

**Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

Сүзнең бер генә мәгънәгә ия булу үзенчәлеге, ягъни бер мәгънә белдерүе бермәгънәлелек була. Бер генә мәгънә белдергән сүзләр – бер мәгънәле сүзләр: *дус, кар, авыл* һ.б. Сүзнең берничә мәгънәгә ия булу үзенчәлеге, ягъни берничә мәгънә белдерүе – күпмәгънәлелек була. Күп мәгънә белдергән сүзләр – күп мәгънәле сүзләр: төшә (*караңгы төшә, фотога төшә, күләгә төшә* һ.б.), чыга (*кояш чыга, теш чыга, җил чыга, кияүгә чыга* һ.б.).

**III. Гамәли-иҗади бирем. (16 балл)**

1. Туган илне саклау турында текст төзеп языгыз (10 җөмлә). *(10 балл)*
2. *Туган* сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. *(6 балл)*

Ту-ган [туғáн]
Хәрефләр: т, у, г, а, н.
Авазлар:
[т] – саңгырау тартык аваз, яңгырау пары – [д];
[у] – калын сузык аваз;
[ғ] – яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [к];
[а] – калын сузык аваз;
[н] – яңгырау тартык аваз, парсыз.

---

5 х., 5 ав.
Бу сүз сингармонизм законына буйсынган.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 38**

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Рәт гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. (**1 балл**)
а) **агачлык**
ә) болыт
б) табигать

2. *Голосовые связки* татарча ничек була? (**1 балл**)
а) йоткылык
ә) кече тел
б) **тавыш ярылары**

3. *Гомер* сүзенең дөрес бирелгән транскрипциясен билгеләгез. (**1 балл**)
а) [ғөмэр]
ә) [ғомөр]
б) **[ғөмөр]**

4. Тексттан *тынлык* сүзенең антонимын табып языгыз. (**1 балл**)
шау-шу

5. *Тилгән* сүзе русча ничек була? (**1 балл**)
а) **коршун**
ә) ястреб
б) орел

6. Сүзләрнең алфавит тәртибендә язылган вариантын билгеләгез. (**1 балл**)
а) ак, ел, көймә, күк, күл, шәһәр, шомырт, чәч, яз
ә) ак, ел, көймә, күл, күк, чәч, шәһәр, шомырт, яз
б) **ак, ел, көймә, күк, күл, чәч, шәһәр, шомырт, яз**

7. Тексттан рус теле аша француз теленнән кергән сүзне табыгыз (**1 балл**)
пәлтә

8. Хәбәре сыйфат сүз төркеме белән белдерелгән җөмләне күчереп языгыз. (**1 балл**)

Аның йөзе **ак**, күзләре **зур**, дулкынланып тора торган чәчләре шомырт кебек **кап-кара**.

9. *Вакыт-вакыт аларның калтыравыклы тавышларын колаклар ишетә* җөмләсендә хәлне билгеләгез. (**1 балл**)

а) **вакыт-вакыт**
ә) аларның
б) тавышларын

10. *Вакыт-вакыт аларның калтыравыклы тавышларын колаклар ишетә* җөмләсендә тәмамлык – **(1 балл)**
а) вакыт-вакыт
ә) колаклар
б) **тавышларын**

## II. Теоретик бирем. (8 балл)

**Алынма сүзләр турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

Бер телгә башка телләрдән кергән сүзләр **алынма сүзләр** дип атала. Татар телендә рус, рус теле аша инглиз теленнән кергән сүзләр, гарәп, фарсы сүзләре еш кулланыла. Рус теле аша Европа телләреннән (француз, итальян, инглиз, немец һ.б.) кергән сүзләр дә күп. Алынма сүзләрнең бер өлеше татар теленә тулысынча яраклашкан: *мич, эшләпә, кәбестә, өстәл, буразна* һ.б. Кайбер алынма сүзләр үзгәртелмичә кулланыла: *телефон, математика, космос, станция* һ.б.

Татар теленең сүзлек составы гел үзгәреп тора. Күп сүзләр искерә, төшеп кала. Телгә яңа сүзләр керә. Татар телендә алынма сүзләр (гарәп-фарсы алынмалары, рус һәм рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр) күп кулланыла. Мәсәлән, гарәп-фарсы алынмалары: *китап, җомга, сәгать, каләм* һ.б.; рус һәм рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр: *спорт, футбол, почта, самолёт, пальто, аспирин, компьютер, шпион, штат* һ.б.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (20 балл)

**1. “*Язгы көн*” темасына хикәя төзеп языгыз.** (10 җөмлә) **(10 балл)**

**2. *Язгы* сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. (4 балл)**

Яз-гы [йа°зғы́]
Хәрефләр: я, з, г, ы.
Авазлар:
[й] – яңгырау тартык аваз, парсыз;
[а°] – калын сузык аваз, бераз иренләштерү төсмере белән әйтелә;
[з] – яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [с];
[ғ] – яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [к];
[ы] – калын сузык аваз;

---

4 х., 5 ав.

**3. *Баш* сүзеннән дүрт тамырдаш сүз ясап языгыз. (4 балл)**

Баш – башлык, башлы, башсыз, башла.

**4. *Кисәкләре* сүзен мәгънәле кисәкләргә таркатыгыз. (2 балл)**

*Зәңгәр күк йөзендә ак болыт* ***кисәкләре*** *йөзә.*

Кисәкләре – кис-әк-ләре

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 33**

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Татар телендә ничә кыска сузык аваз бар? (**1 балл**)
   а) 3
   ә) **4**
   б) 6

2. Ясалу урыны буенча **[**ч**]** тартыгы – (**1 балл**)
   а) ирен-теш тартыгы
   ә) кече тел тартыгы
   б) **тел алды тартыгы**

3. *Елаган* сүзенең дөрес язылган транскрипциясен билгеләгез. (**1 балл**)
   а) [йыла°ған]
   ә) **[йылаған]**
   б) [йылаган]

4. [у] сузык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз. (**1 балл**)
   а) [у] – арткы рәт, кыска, иренләшкән сузык аваз
   ә) [у] – алгы рәт, озын, иренләшкән сузык аваз
   б) [у] – **арткы рәт, озын, иренләшкән сузык аваз**

5. Тексттан чикләү мәгънәсен белдергән кисәкчә булган җөмләне күчереп языгыз. **(1 балл)**

**Ул бик әкрен *генә* төпсез һәм салкын диңгез төбенә төшеп бара...**

6. Татар телендәге рус алынмаларын билгеләгез. (**1 балл**)
   а) спорт, чемпион, кекс
   ә) **эскәтер, эшләпә, сумала**
   б) вермишель, макарон, матрос

7. Ымлык булган җөмләне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) Ул гүя кайгылы иде.
   ә) Менә шуннан бирле һаман көтә.
   б) **Чү! Ишек алдында кемнәр?**

8. *Аның инде кул, аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле тарталар* җөмләсендә тиңдәш кисәкләрне билгеләгез. **(2 балл)**

**Тиңдәш ияләр:** кул, аяклары
**Тиңдәш хәбәрләр:** сизми, кузгалмый, салкын, тарталар.

9. *Паспорт, метро, парад* сүзләре **(1 балл)**

а) рус алынмалары

ә) **француз теленнән кергән сүзләр**

б) инглиз теленнән кергән сүзләр

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

**Сүз төзелеше, тамыр һәм кушымчалар турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

**Сүз төзелеше** сүзнең мәгънәле кисәкләрен өйрәнә. Тамыр һәм кушымча **сүзнең мәгънәле кисәкләре** дип атала. Сүз бер яки берничә мәгънәле кисәктән тора: *уен, уен-чык, уен-чык-лар.* **Тамыр** – сүзнең төп мәгънәсен белдерә торган кисәк. Кушымчалар тамырга бер-бер артлы ялганалар һәм сүзнең лексик мәгънәсен (сыйныф-таш) яки формасын (сыйныфны) үзгәртәләр.

Кушымчалар ике төргә бүленә:

1) **Сүз ясагыч кушымчалар** (яңа сүз ясыйлар): -лык/-лек, -даш/-дәш, -таш/-тәш, -ма/-мә, -лы/-ле, -гы/-ге, -кы-/-ке, -сыз-/-сез, -чы/-че, -ла/-лә һ.б.

2) **Форма ясагыч кушымчалар** (сүзнең формасын үзгәртәләр): -кай/-кәй, -чык/-чек, -лар/-ләр, -нар/-нәр, -рак/-рәк, -гылт/-гелт, -ынчы, -енче, - ау/-әү, -ды/-де, -ты/-те, -ган/-гән, -кан/-кән, -ачак/-әчәк, -мый/-ми, -ма/-мә һ.б.

Форма ясагыч кушымчалар эчендә **төрләндергеч кушымчалар** да бар. Алар да сүзнең төрле формасын ясыйлар, сүзләрне төрләндерәләр яки сүзләрне, җөмләләрне бәйләү өчен хезмәт итәләр: *әнине, әнидә, әнием, әниең, әниегезгә, барам, бармыйм, барасың, барачакмын* һ.б. Төрләндергеч (бәйләгеч) кушымчаларга килеш кушымчалары, тартым кушымчалары, зат-сан кушымчалары керә.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (18 балл)

1. “*Бик сагынсам сине, күккә карыйм, Син үзең дә ай күк, и әни!”* дигән темага текст төзеп языгыз. (10 җөмлә) (10 балл)

2. *Буран* сүзенә фонетик анализ ясагыз. *(5 балл)*

Бу-ран [бура́н]

Х ә р е ф л ә р: б, у, р, а, н.

А в а з л а р:

[б] – парлы яңгырау тартык аваз, саңгырау пары – [п], ирен-ирен тартыгы;

[у] – арткы рәт, озын, иренләшкән сузык аваз;

[р] – парсыз яңгырау тартык аваз, тел алды тартыгы.

[а] – арткы рәт, озын, иренләшмәгән сузык аваз;

[н] – парсыз яңгырау тартык аваз, тел алды тартыгы.

________

5 х., 5 ав.

Бу сүз сингармонизм законына буйсынган.

3. Фигыльләрнең нигезеннән хәзерге заман хикәя фигыльләр ясагыз. (3 балл)

Эшлә-, укы-, бие-, җырла-, мен-, җый-, төзе-, сөйлә-, кал-.

Эшлә- – эшли, укы- – укый, бие- – бии, җырла- – җырлый, мен- – менә, җый- – җыя, төзе- – төзи, сөйлә- – сөйли, кал- – кала.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары* 2022-2023 нче уку елы 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. Тестны эшләгез. (10 балл)

1. [а] тартык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз.
   а) [а] – иренләшкән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы
   ә) [а] – иренләшмәгән, урта күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы
   б) **[а] – иренләшмәгән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы**

2. Ясалу урыны буенча **[й]** тартыгы –
   а) тел арты тартыгы
   ә) **тел уртасы тартыгы**
   б) тел алды тартыгы

3. Ясалу ысулы буенча **[й]** тартыгы –
   а) йомык
   ә) **өрелмәле**
   б) ярымйомык

4. [р] тартык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз.
   а) **[р] – парсыз яңгырау, сонор, калтыраулы, тел алды, авыз тартыгы**
   ә) [р] – парсыз яңгырау, сонор, ярымйомык, тел арты, авыз тартыгы
   б) [р] – парсыз яңгырау, йомык, тел алды, авыз тартыгы

5. Җөмләгә төшеп калган дифтонгларны языгыз.
   Мал_ ж_ көне а_лга к_та.
   Мал**ай җәй** көне а**вы**лга (а**wы**лга) к**ай**та.

6. Күчерелмә мәгънәле сүз булган сүзтезмәне табыгыз.
   а) зәңгәр яулык
   ә) **зәңгәр бәхет**
   б) зәңгәр күк

7. Ойконимны билгеләгез. .
   а) **Чистай шәһәре**
   ә) Айгөл
   б) Кара диңгез

8. Тезмә кушма җөмләне билгеләгез.
   а) Дөрес, кайчагында фриц, килеп, безнең өскә бомбалар ыргытып китә.

ә) Кайвакыт без шулай яшел чирәм өстенә түгәрәкләнеп утырабыз да кесәдә аунаган иске хатларны кат-кат укыйбыз, карточкаларны чыгарып карыйбыз.

б) **Димәк, вакыт күп, ә эш аз.**

9. *Без хәзер фронтка якын гына бер җирдә резервта торабыз* җөмләсендә *резерв* сүзенең аңлатмасын билгеләгез.

а) солдат, рядовой гаскәри

ә) дәүләтнең барлык кораллы көчләре

б) **гаскәри хезмәттән запаска җибәрелгән кешеләр**

10. *Без карточкаларны чыгарып карыйбыз* җөмләсендә *карточкаларны* сүзенең дүрт грамматик мәгънәсен әйтегез.

1) исем сүз төркеме, 2) күплек санда, 3) төшем килешендә, 4) җөмләдә тәмамлык булып килгән.

## II. Теоретик бирем. (15 балл)

**Омонимнар турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

Әйтелешләре һәм язылышлары бер үк, әмма мәгънәләре төрле булган сүзләр **омонимнар** (аваздаш сүзләр) дип йөртелә: *чаба – малай чаба, бабай печән чаба, кунаклар кул чаба*. Күп мәгънәле сүзләрдән аермалы буларак, омоним сүзләрнең мәгънәләре арасында бәйләнеш булмый: *йөз – йөз (акча берәмлеге), йөз (фигыль), йөз (бит).*

Омонимнарның дүрт төре бар:

1) саф лексик омонимнар – аваз составы ягыннан бер-берсенә охшаш тамыр сүзләр: *бит – кеше бите* (лицо); *дәфтәр бите* (лист тетради), *бит* (кисәкчә);

2) омофоннар – язылышлары төрле, әйтелешләре бер үк булган сүзләр: *бал авыз, балавыз; карт аю, картаю*;

3) омографлар – язылышлары бер, әйтелешләре төрле булган сүзләр: *бүлмә́, бү́лмә; басма́, ба́сма;*

4) омоформалар – билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр: *көзге* – сыйфат (осенний), *көзге* – исем (зеркало); *үпкәләр* – исем (лёгкие), *үпкәләр* – фигыль (обидится).

## III. Гамәли-иҗади бирем. (25 балл)

1. “*Солдатка хат”* дигән темага текст төзеп языгыз. (10 җөмлә) (10 балл)
2. *Юаныч* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (6 балл)

Юаныч [йуаны́ч]

Ю-а-ныч

Х ә р е ф л ә р: ю, а, н, ы, ч

А в а з л а р:

[й] – парсыз яңгырау тартык аваз, өрелмәле, сонор, тел уртасы тартыгы;

[у] – иренләшкән, югары күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы;

[а] – иренләшмәгән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы;

[н] – парсыз яңгырау тартык аваз; сонор, тел алды, борын тартыгы;

[ы] – иренләшмәгән, урта күтәрелешле, кыска, арткы рәт сузыгы;

[ч] – саңгырау, яңгырау пары – [ж], өрелмәле, тел алды, авыз тартыгы.

5 х., 6 ав.
Бу сүз сингармонизм законына буйсынган.

3. *Ак* һәм *кара* сүзләре, метафора булып килерлек итеп, икешәр җөмлә төзегез. (4 балл)
Мисал өчен метафоралар: *ак бәхет, кара кайгы.*

4. Бирелгән фразеологизмнарның русча вариантларын языгыз. (5 балл)

Мәсәлән: теленңне йотарсың – пальчики оближешь, алтын куллы – мастер на все руки, бер чыбыктан сөрелгән – одного поля ягода, кәкре каенга терәтү – обвести вокруг пальца, уртак тел табу – находить общий язык.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Басым соңгы иҗеккә төшми торган сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) яшерден, мәдрәсәдә
   **ә) буялмаган, кайдан**
   б) скрипкада, чиерткәләвен

2. *Бәдретдин* сүзендәге сузык авазлар – (**1 балл**)
   **а) иренләшмәгән, алгы рәт сузыклары**
   ә) иренләшкән, алгы рәт сузыклары
   б) иренләшмәгән, арткы рәт сузыклары

3. *Бәдри* сүзендәге сузык авазлар – (**1 балл**)
   а) [ә] - озын сузык, [и] - кыска сузык
   ә) икесе дә кыска сузык
   **б) икесе дә озын сузык**

4. Фарсы теленнән алынган компонентлар булган сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) **даруханә, хәбәрдар**
   ә) мәктәп, әдәбият
   б) чәчәкле, сәламәтлек

5. *металл* сүзенә тартым кушымчасы ялгануның дөрес вариантын билгеләгез. (**1 балл**)
   а) металлам
   ә) металлым
   **б) металым**

6. *календарь* сүзенә тартым кушымчасы ялгануның дөрес вариантын билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) календаребыз**
   ә) календаребез
   б) календарыбыз

7. *Бәдретдин скрипканы кулына алуга, без аңа гаҗәпләнеп карадык* җөмләсе – (**1 балл**)
   а) гади җөмлә
   **ә) иярченле кушма җөмлә**

б) тезмә кушма җөмлә

8. *Без аның әнисенә карадык, әмма ана үзенең улына бик яратып, сокланып карап утыра иде* җөмләсе – (**1 балл**)

а) синтетик иярченле кушма җөмлә

**ә) тезмә кушма җөмлә**

б) аналитик иярченле кушма җөмлә

9. *Без аның кубызда уйнавын, мандолина чиерткәләвен белә идек* җөмләсендә мандолина сүзе җөмләнең кайсы кисәге? (**1 балл**)

а) **тәмамлык**

ә) ия

б) хәл

10. Кайсы кагыйдә дөрес түгел? (**1 балл**)

а) фигыльнең юклык кушымчасына (-ма,-мә) басым төшми

ә) кайбер күрсәтү һәм сорау алмашлыкларында басым беренче иҗеккә төшә

**б) II зат боерык фигыльләрдә басым соңгы иҗеккә төшә**

## II. Теоретик бирем. (10 балл)

**Пассив лексика турында языгыз һәм бишәр мисал китерегез.**

Пассив лексика дип бүгенге көндә аралашу, аңлашу өчен кирәге булмаган, сирәк кулланыла торган сүзләр атала. Алар инде тулысынча кулланылыштан чыккан яки чыгып бара, я яңа гына барлыкка килеп, киң кулланылышка кереп өлгермәгән. Пассив сүзлек фонды ике зур төркемгә аерыла: искергән сүзләр һәм яңа сүзләр.

Искергән сүзләр:

Тарихи сүзләр. Кулланылыштан төшеп калган предмет, күренеш, төшенчәләрнең атамалары: алпавыт, чабата, кабилә, пейджер, патша һ.б.

Архаизмнар. Нindидер предмет, күренеш, төшенчәнең искергән атамалары: ат – исем, болак – чишмә, елга, берлә – белән, еглау – елау, Итил – Идел һ.б.

Неологизмнар – телдә аерым бер чорда яңа күренеш, төшенчәләрне атау өчен барлыкка килгән сүзләр: глобаль челтәр, инвестор, инфраструктура, лизинг, чартер һ.б.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (30 балл)

1. *Чиерткәләвен* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (15 балл)

чи-ерт-кә-лә-вен – [чи-йәрт-кә-лә-wә́н]

хәрефләр: ч, и, е, р, т, к, ә, л, ә, в, е, н

авазлар:

[ч] – парлы саңгырау, яңгырау пары [ж], өрелмәле, тел алды, авыз тартыгы;

[и] – алгы рәт, югары күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;

[й] – парсыз яңгырау, сонор, өрелмәле, тел уртасы, авыз тартыгы;

[э] – алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска сузык аваз;
[р] – парсыз яңгырау, сонор, калтыраулы, тел алды, авыз тартыгы;
[т] – парлы саңгырау, яңгырау пары [д], йомык, тел алды, авыз тартыгы;
[к] – парлы саңгырау, яңгырау пары [г], йомык, тел арты, авыз тартыгы;
[ә] – алгы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;
[л] – парсыз яңгырау, сонор, ярымйомык, тел алды, авыз тартыгы;
[ә] – алгы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;
[w] – парсыз яңгырау, сонор, өрелмәле, ирен-ирен, авыз тартыгы;
[э] – алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска сузык аваз;
[н] – парсыз яңгырау, сонор, ярымйомык, тел алды, борын тартыгы;

---

12 хәреф, 13 аваз. Сингармонизм законына буйсына.

2. Тексттагы туры сөйләмле җөмләләрне кыек сөйләмгә әйләндереп языгыз. (5 балл)

1) Бәдретдин дусларына күрсәтәсе бер әйбере барлыгын әйтте.
2) Дуслары скрипканы кайдан алуы белән кызыксындылар.
3) Бәдретдин скрипканы үзе ясавын хәбәр итте.
4) Дуслары Бәдридән нигә моңарчы яшерүен сорадылар һәм аның мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкасында уйный алган булуын әйттеләр.
5) Оста барда кулны тыярга кирәклеген искәртте Бәдретдин тыйнак кына.

3. “Оста барда кулың тый!” темасына 10 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (10 балл)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 40**

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Әдәби әйтелешне үзгәртеп сөйләүнең сәбәбен билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) орфография кагыйдәләрендә бирелгән аңлатмаларга ияреп, дөрес язылганны ялгыш уку**
   ә) сүзләрдә басымның соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин булуы
   б) сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язу

2. Төшерелмә дифтонглар булган сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) авыл, тавыш, өе
   **ә) кыңгырау, Сәйдә, уйнап**
   б) яши, сәер, юклыгын

3. Йомык тартык авазлар гына булган сүзне билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) тап**
   ә) сиксән
   б) кил

4. Тел алды тартыклары гына булган сүзне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) улының
   ә) кайткан
   **б) тышына**

5. Рәт гармониясе сакланмаган сүзләр генә булган вариантны билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) Халисә, конверт, иңбашына**
   ә) сәер, Мөхәммәтҗан, яши
   б) почта, фамилия, велосипед

6. Ирен ассимиляциясенә караган мисалны билгеләгез. (**1 балл**)
   а) кайтканнар
   ә) борып
   **б) унбер**

7. Кушымча ялгау юлы белән ясалган сүзләр булмаган рәтне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) басма, Алансу
   **ә) тавышыннан, иңбашына**
   б) Мөхәммәтҗан, җәйге

8. Текстның 1, 2 җөмләләрендә кулланылган сыйфат фигыльләрне билгеләгез. (**1 балл**)

**а) килгән, ясалган**

ә) язылган, булды

б) сәер, басма

9. *Кемгә булыр икән бу хат?* җөмләсендә *бу* сүзе җөмләнең кайсы кисәге? **(1 балл)**

**а) аергыч**

ә) ия

б) хәл

10. Улының да, кызының да балалары җәйге ялга авылга кайтканнар, качышлы уйнап яталар җөмләсенең төрен билгеләгез. **(1 балл)**

**а) гади җөмлә**

ә) тезмә кушма җөмлә

б) иярченле кушма җөмлә

## II. Теоретик бирем. (10 балл)

**Рәвеш, аның төркемчәләре турында языгыз һәм өчәр мисал китерегез.**

Рәвеш – мөстәкыйль сүз төркеме. Ул, эш яки хәлнең билгесен белдереп, ничек? ник? кайда? кайчан? күпме? никадәр? кебек сорауларга җавап бирә. Рәвеш җөмләдә күбрәк фигыльне (әкрен барды), сирәгрәк сыйфатны (татарча китап) һәм рәвешне (шактый озак) ачыклап килә.

Рәвеш – төрләнми торган сүз төркеме. Кайбер рәвешләр, сыйфатлар кебек, төп, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәсендә кулланыла: тиз – тизрәк, бик тиз; әкрен – әкренрәк, иң әкрен; ерак – ераграк, бик ерак.

Мәгънәләренә карап, рәвешләрне 6 төркемчәгә бүләләр:

1. саф рәвешләр эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдерәләр, ничек? ни рәвешле? сорауларына җавап бирәләр: тиз, әкрен, җәяү һ.б.;
2. урын рәвешләре эш-хәлнең үтәлү урынын, юнәлешен белдерәләр, кая? кайда? сорауларына җавап бирәләр: югары, түбән, ерак һ.б.;
3. вакыт рәвешләре эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерәләр, кайчан? соравына җавап бирәләр: хәзер, кичә, бүген һ.б.;
4. күләм-чама рәвешләре эш-хәлнең үтәлү күләмен, дәрәҗәсен белдерәләр, никадәр? күпме? сорауларына җавап бирәләр: шактый, аз, еш һ.б.;
5. сәбәп-максат рәвешләре эш-хәлнең үтәлү сәбәбен, максатын белдерәләр, ник? ни өчен? нинди максат белән? сорауларына җавап бирәләр: тиккә, юри, юкка һ.б.;
6. охшату-чагыштыру рәвешләре эш-хәлне нәрсә белән булса да чагыштыру аша ачыклыйлар. Алар -дай/-дәй, -тай/-тәй, -ча/-чә кушымчалары ярдәмендә ясалалар, ничек? нәрсәдәй? сорауларына җавап бирәләр: таудай, бәйрәмчә, татарча һ.б.

**III. Гамәли-иҗади бирем. (20 балл)**

1. *Кемгә булыр бу билгесез хат?* җөмләсендәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. (5 балл)

кемгә – сорау алмашлыгы, ю.к., тамыр сүз, җөмләдә тәмамлык булып килгән.

булыр – хикәя фигыль, затланышлы, барлыкта, билгесез киләчәк заманда, 2 зат берлек санда, тамыр сүз, җөмләдә хәбәр булып килгән.

бу – күрсәтү алмашлыгы, б.к., тамыр сүз, җөмләдә аергыч булып килгән.

билгесез – нисби сыйфат, *хат* сүзен ачыклаган, ясалышы ягыннан ясалма сүз, җөмләдә аергыч булып килгән.

хат – уртаклык исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, тамыр сүз, җөмләдә ия булып килгән.

2. Алфавитта урнашу тәртибенә карап, хәрефләрне табыгыз, яшерелгән мәкальне языгыз. (7 балл)

Баладан бәхетең булса, карт көнеңдә яшь итәр.

3. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. (8 балл)

Ванька язып тутырылган битне дүрткә бөкләде һәм аны алдагы көнне бер тиенгә алган конвертка салды... Бераз уйлап торгач, ул каләмне карага манып алды һәм адресны язды:

Авылга бабайга.

Аннан соң башын кашып алды, уйланып торды да өстәп язды: “Константин Макарычка”.

Язарга комачауламауларына сөенеп, ул бүреген (башлыгын) киде һәм, тунын кия-кия, күлмәкчән генә, урамга йөгереп чыкты...

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50**

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Тартык авазларга бирелгән характеристакаларның хаталысын билгеләгез. **(1 балл)**
   а) [w] – ирен-ирен, өрелмәле
   **ә) [н] – тел алды, йомык**
   б) [к] – кече тел, йомык

2. Басым ахыргы иҗегенә төшә торган сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) каракны, малайларныкы**
   ә) елдагычы, кабинага
   б) күрмәдем, курыкмыйм

3. Орфографик принципларга туры килгән мисалларны табыгыз. (**1 балл**)
а) фонетик принцип
ә) морфологик принцип
б) тарихи-традицион принцип
в) график принцип

   1) әнкәй, унбер
   2) майор, биология
   3) тәрәзә, гөл
   4) 4 нче йорт, җылылык 18° тан югары

а 3; ә 1; б 4; в 2

4. Хәл фигыльләр рәтен билгеләгез. (**1 балл**)
   **а) менгергәч, балкытып**
   ә) кайтыргамы, йөгергән
   б) урларга, курыкмыйм

5. Фразеологик сүзтезмәне билгеләгез. (**1 балл**)
   а) мыек чолгыйлары
   **ә) киресенә катып тора**
   б) шофёр агай янына чүмәште

6. *чүмәште* сүзенең синонимын билгеләгез. (**1 балл**)
   а) егылды
   ә) утырды

**б) чүгәләде**

7. *көймә борыны* сүзтезмәсе күчерелмә мәгънәнең кайсы төренә карый? (**1 балл**)

**а) метафора**
ә) метонимия
б) синекдоха

8. Фарсы теленнән кергән алынма сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)

а) карлыгач, малай, карак, чокыр, юртак
ә) тәртип, хат, рәсем, сәгать, каләм
**б) сәүдә, шәһәр, каһарман, гәүһәр, әсәр, әсир**

9. *Малай бик батыр кыяфәттә борынын чөйде* җөмләсендә *борынын* сүзе җөмләнең кайсы кисәге? (**1 балл**)

**а) тәмамлык**
ә) ия
б) хәл

10. Хәбәр ителә торган фикерне эмоциональ яктан бәяләүне белдерә торган модаль сүзләрне билгеләгез. (**1 балл**)

а) **гаҗәп, кызганыч, үкенеч**
ә) әлбәттә, һичшиксез, бәхәссез
б) бәлки, бугай, мөгаен

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

**Аваз ияртемнәре турында языгыз һәм алты мисал китерегез.**

Аваз ияртемнәре – төрле тавыш һәм авазларга охшатып ясала торган сүзләр. Аваз ияртемнәре мөстәкыйль сүз төркемнәренә керә. Алар кеше, кош-корт, хайван, җансыз предметлар, табигать күренешләре чыгарган тавышларны белдерә.

Кешенең сөйләм органнарында барлыкка килгән тавышларга (кых-кых – йөткерү, эһ-м-м-м – тамак кыру, тә-тә-тә – күп сөйләшү һ. б.), кеше хәрәкәте тудырган тавышларга (лап-лоп – аяк тавышы, дөбер-шатыр – авыр әйберләрне кузгату, күчерү һ. б.), йорт хайваннары, ерткыч җәнлекләр, кош-корт, бөҗәкләр чыгарган авазларга (мияу – мәче кычкыру, у-у-у – бүре улау, кикрикүк – этәч кычкыру, без-без – чебен безелдәү һ. б.) охшатып ясалган аваз ияртемнәре була.

Аваз ияртемнәреннән мөстәкыйль мәгънәле сүзләр дә ясала: кыштырдау, шыгырдау, безелдәү, гөжләү, ялт-йолт итү һ.б.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (35 балл)

1. *елдагыча* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (10 балл)

ел-да-гы-ча – [йыл-да-гы́-ча]
хәрефләр: е, л, д, а, г, ы, ч, а

авазлар:
[й] – парсыз яңгырау, сонор, өрелмәле, тел уртасы, авыз тартыгы;
[ы] – арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска сузык аваз;
[л] – парсыз яңгырау, сонор, ярымйомык, тел алды, авыз тартыгы;
[д] – парлы яңгырау, саңгырау пары [т], йомык, тел алды, авыз тартыгы;
[а] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;
[ғ] – парлы яңгырау, саңгырау пары [к], йомык, кече тел, авыз тартыгы;
[ы] – арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән, кыска сузык аваз;
[ч] – парлы саңгырау, яңгырау пары [ж], өрелмәле, тел алды, авыз тартыгы;
[а] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, озын сузык аваз;

---

8 хәреф, 9 аваз. Сингармонизм законына буйсына.

2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз (10 балл)

Карлыгачны, елдагыча, йөк машинасының әрҗәсенә менгергәч, малай кабинага чүмәште.

Карлыгачны алам да Җиләктау чокырына качам да китәм, берәү дә табалмый!

3. “Ат чабышы – Сабантуйның күрке” темасына 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (15 балл)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең *җаваплары***
**2022-2023 нче уку елы**
**11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 46**

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. *соңгылар* сүзендәге сузык авазларга бирелгән характеристикаларның хаталысын билгеләгез. (**1 балл**)
а) [о] – иренләшкән, урта күтәрелешле, кыска, арткы рәт сузыгы
**ә) [ы] – иренләшкән, урта күтәрелешле, кыска, арткы рәт сузыгы**
б) [а] – иренләшмәгән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы

2. Гарәп-фарсы алынмаларының рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр белән бирелгән синонимнарын тоташтырыгыз.

| | |
|---|---|
| җәдвәл | таблица |
| җөмһүрият | республика |
| әмер | приказ |
| мантыйк | логика |
| матбуга | типография |

3. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. (**1 балл**)
а) болар
**ә) нидер**
б) беркем

4. Инфинитивны билгеләгез. (**1 балл**)
а) кергәндә
**ә) алмаска**
б) узып киткән

5. Сыйфат фигыльне билгеләгез. (**1 балл**)
**а) эшләүче**
ә) боерулы
б) багыйк

6. *аягурә* рәвешенең төркемчәсен билгеләгез. (**1 балл**)
а) сәбәп-максат
ә) күләм-чама
**б) саф**

7. Затланышсыз фигыльләрне билгеләгез. (**1 балл**)
**а) тикшереп, керү**
ә) каушата, багыйк

б) булса, күрсәтегез

8. Ярдәмлек сүз төркемнәрен билгеләгез. (**1 балл**)

а) кисәкчәләр, ымлыклар
**ә) бәйлекләр, теркәгечләр**
б) аваз ияртемнәре

9. *Комиссиядәгеләр үзара чыш-пыш килә башлады* җөмләсендә комиссиядәгеләр сүзе – (**1 балл**)

а) урын хәле
**ә) ия**
б) аергыч

10. *Ул сынау залына килеп кергәндә, озын, зифа буйлы бер хатын, аягүрә басып, комиссия әгъзаларына нидер аңлата иде* җөмләсенең төрен билгеләгез. (**1 балл**)

**а) синтетик иярченле кушма җөмлә**
ә) аналитик иярченле кушма җөмлә
б) тезмә кушма җөмлә

## II. Теоретик бирем. (10 балл)

**Тезмә кушма җөмләләр турында языгыз һәм һәр төренә өчәр мисал китерегез.**


Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала. Тезмә кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләр үзара тезүче теркәгечләр һәм интонация ярдәмендә бәйләнәләр. Гади җөмләләре тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә теркәгечле тезмә кушма җөмлә дип атала. Мәсәлән: Маһирә озак тыңлап торган, ләкин беркем дәшмәгән.

Гади җөмләләре үзара интонация ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә теркәгечсез тезмә кушма җөмлә дип атала. Мәсәлән: Алар бер карарга килгәннәр, җеннәр үз почмакларына таралышканнар. Менә бал корты чәчәккә килеп кунды — чәчәк сыгылып төште.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (26 балл)

1. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз (5 балл)

[1)]*Ул сынау залына килеп кергәндә, озын, [2)]зифа буйлы бер хатын, аягүрә басып, комиссия әгъзаларына нидер аңлата иде.*




2. Татар халык мәкален языгыз. (6 балл)

Кешегә иң кирәге – ягымлы йөз, җылы сүз.

3. “Сынау” темасына 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (15 балл)